| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Кукмара ш.

№ 223

24 май 2019 ел

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы, “Татарстан Республикасы Җир кодексының 321 статьясы буенча бушлай җир кишәрлекләре алырга хокуклы гражданнарның исемлеген әзерләү тәртибе турында”гы Кукмара муниципаль районы Советының 2011нче елның 27нче декабрендә кабул ителгән №100 карары буенча буенча бушлай җир кишәрлекләре алырга хокуклы гражданнарның исемлеген әзерләү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында.

Бушлай җир кишәрлекләре алырга хокуклы гражданнарның исемлеген әзерләү Тәртибен Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы, Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы буенча Кукмара муниципаль районы Советының 2011нче елның 27нче декабрендә кабул ителгән №100 карары буенча тәртипкә китерү максатыннан Кукмара муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы (алга таба- Тәртип), “Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы буенча бушлай җир кишәрлекләре алырга хокуклы гражданнарның исемлеген әзерләү тәртибе турында”гы Кукмара муниципаль районы Советының 2011нче елның 27нче декабрендә кабул ителгән №100 карары буенча бушлай җир кишәрлекләре алырга хокуклы гражданнарның исемлеген әзерләү Тәртибенә( Кукмара муниципаль район Советы 23.08.2013нче елгы №35 карары белән кабул ителгән үзгәрешләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3нче пунктны алдагы редакциядә күрсәтергә:

“3. Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы 3нче пунктында күрсәтелгән гражданнар үзләренә бирелгән җир кишәрлегеннән бер мәртәбә шәхси торак төзергә, шәхси хуҗалык (йорт янындагы җир

кишәрлеге) алып барырга, бакчачылык, яшелчәчелек белән шөгыльләнергә хокуклы, яки андый гражданнарның милкендә булган торак йорт урнашкан җир кишәрлекләрен тапшырырга хокукыннан файдалана алалар.

Татарстан Республикасы Җир кодексының 321 статьясы 3нче пунктында каралган нигезләмәләр буенча җир кишәрлеге милекчеләре булган балалар, алар балигъ яшькә җиткәч, күрсәтелгән нигезләмәләр буенча бер мәртәбә җир кишәрлеге алу (тапшыру) хокукларын саклыйлар.

1.2. 9нчы пунктны “ һичшиксез вәкаләтле орган яки күпфункцияле үзәк аша” дигән сүзләр белән тулыландырырга;

1.3.14нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

“14. Җир кишәрлегендә бер мәртәбә шәхси торак төзергә, шәхси хуҗалык (йорт янындагы җир кишәрлеге) алып барырга, бакчачылык, яшелчәчелек белән шөгыльләнергә хокуклы гражданнар исемлегенә кертү турындагы карар кабул итү өчен гариза бирүче гариза биргәннән соң, 14 көннән соңга калмыйча, түбәндәге документлар тапшырыла:”;

1.4. 17нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

“17. Гариза тапшырылганнан соң 30 көн эчендә, вәкаләтле орган гариза тапшыручыны шәхси торак төзергә, шәхси хуҗалык (йорт янындагы җир кишәрлеге) алып барырга, бакчачылык, яшелчәчелек белән шөгыльләнергә хокуклы гражданнар исемлегенә( алга таба- исемлек) кертү турында карар кабул итә һәм гариза бирүчегә уникаль исәп номеры билгели.”:

1.5. 18 нче пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

“18. Гариза тапшыручы әлеге Тәртип статьясының 14нче пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, яки тапшырылган документлар шәхси торак төзү, шәхси хуҗалык (йорт янындагы җир кишәрлеге) алып бару, бакчачылык, яшелчәчелек белән шөгыльләнү хокукы булуы расланмаганда, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы исемлеккә кертүне кире кагу турында карар кабул итә.

1.6. 19нчы пунктта “ дача төзелеше” дигән сүзне алырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы мәгълүмати- телекоммуникацион “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылган көннән башлап үз көченә керә.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев